*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ

**ҖАВАПЛАРЫ**

(2023-2024 нче уку елы)

**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Яңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) усак
   ә) каен
   б) чыршы
   **в) имән**

2. Калын сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) сарымсак**
   ә) чөгендер
   б) кишер
   в) помидор

3. Нокталар урынына о хәрефе языла торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) т..ньяк
   **ә) й..зак**
   б) яңг..р
   в) җ..рчы

4. Юлдан-юлга күчереп булмый торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кояш
   ә) болыт
   **б) дөнья**
   в) ябалак

5. ***Тирән*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) биек
   **ә) сай**
   б) тәбәнәк
   в) киң

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) башкала**
   ә) көлмәк
   б) башлык

в) бала-чага

7. Чыгыш килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) мәктәпнең
**ә) мәктәптән**
б) мәктәпне
в) мәктәпкә

8. Үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) барам
ә) барырмын
б) барачакмын
**в) бардым**

9. Алмашлыкны билгеләгез. **(2 балл)**
а) укытучы
ә) батыр
**б) алар**
в) укыйм

10. Сорау җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Без урамда уйныйбыз.
**ә) Бүген көн салкынмы?**
б) Укучылар, дәфтәргә языгыз!
в) Бүген көн искиткеч!

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә. **(5 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Авазларны **эйтәбез** һәм ишетәбез. [а], [о], [у], [ы] – **калын** сузык авазлар. -ма/-мә кушымчасына **басым** төшми. Кечкенә, нәни, бәләкәй – **синоним** сүзләр. Нечкә әйтелешле сүзгә **нечкә** кушымча ялгана. -ның/-нең – **иялек** килеше кушымчасы. **Сан** предметның санын, исәбен белдерә. Хикәя фигыльләр өч заманда кулланыла: хәзерге, үткән һәм **киләчәк**.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(3 балл)**

снег – **кар**
снежок – **кар бөртеге**
лыжи – **чаңгы**
санки – **чана**
варежки – **бияләй**
шуба – **тун**

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(5 балл)**

Бүген кар күп я**у**ган. Рәшитне**ң** әнисенә **э**ш арткан. Ул тротуар чистартырга урамга чыкты. Рәшит тә үзе кебек к**е**чкенә к**ө**рәк алды да кар к**ө**ри башлады. Аның к**ө**рәге фанер**д**ан эшлә**н**гән – жи**ң**ел. (*Абдулла Әхмәттән*)

2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(3 балл)**

күп – **аз** арткан – **кимегән** чыкты – **керде**

2.2. Зат алмашлыкларын күчереп языгыз, килешләрен билгеләгез. **(2 балл)**

(**ул** – б.к., **аның** – и.к.).

3. Кышын буш вакытларыгызны сез ничек үткәрәсез? Шул хакта 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(10 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Саңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәктәп
   ә) ишек
   б) кыңгырау
   в) акбур

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Илнур
   ә) Алмазия
   б) Гөлчәчәк
   в) Мансур

3. Җөмләдәге кече тел (увуляр) **[к]** авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер.* (Мәкаль)
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   в) 4

4. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.* (Мәкаль)
   а) һөнәр
   ә) ашарга
   б) сорамый
   в) ашата

5. ***Саран*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тар
   ә) тырыш
   б) тыйнак
   в) юмарт

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) чүлмәк

ә) билбау
б) кура җиләге
в) савыт-саба

7. Җөмләдәге исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**
*Сандугачны сайрарга өйрәтмиләр.* (Мәкаль)
а) баш килеш
ә) иялек килеше
б) юнәлеш килеше
в) төшем килеше

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Егет кешегә* ***җитмеш*** *төрле һөнәр дә аз.* (Мәкаль)
а) исем
ә) сыйфат
б) сан
в) фигыль

9. Боерык фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Кәкре агачсыз урман булмый.
ә) Агачтан яфрак төшми тормый.
б) Алма агачыннан ерак төшми.
в) Алманың кызылына алданма.

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Акылсыз башка алтын бүрек файда бирми.* (Мәкаль)
а) башка
ә) акылсыз
б) бүрек
в) алтын

## II. Башыгызны эшләтегез.

Хәрефләрне дөрес итеп урнаштырып, мәкальне укыгыз һәм языгыз. **(5 балл)**

ЗНИДЕЕГҢ РШЫЫП НЛЕӘБ ТБАЫЛОГП МУЙБЛЫ.

___________________________________________________________

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле авазны һәм сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

В хәрефе [в] һәм [ __ ] авазларын белдерә. Сүзләрнең мәгънәләре _______________ сүзлекләрдә күрсәтелә. Бер тамырдан ясалган сүзләр

______________ сүзләр дип атала. -га/-гә – ______________ килеше кушымчасы. Мин, син, ул – __________ алмашлыклары. Ия ______________ килештәге зат алмашлыклары белән белдерелә ала. Җөмләләр ______________ уйны белдерә. ______________ кисәкләр бер-берсе белән тезүле бәйләнештә килә.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(3 балл)**

Рано вставай.
Не бойсы воды – мойся!
Вовремя пей, вовремя ешь.
(*Самуил Маршак*)

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

Без га..ләбез белән спорт яратабыз. Көн саен иртән паркта йөгерәбез. ..нем белән абыем й..з..ргә яраталар. Мин хоккей белән ш..г..льләнәм.

..әр көнне без җиләк-җимеш ашыйбыз. Мин баллы ризык ашамыйм. Ул т..шләргә зыянлы.

2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(3 балл)**

көн – ___________ баллы – ___________ зыянлы – ___________

2.2. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(3 балл)**

йөгерү – ___________ баллы – ___________ зыянлы – ___________

3. Сез нинди ризыклар ашарга яратасыз? Дөрес туклану ни өчен кирәк? Шул хакта 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Саңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәктәп
   **ә) ишек**
   б) кыңгырау
   в) акбур

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Илнур
   ә) Алмазия
   **б) Гөлчәчәк**
   в) Мансур

3. Җөмләдәге keче тел (увуляр) **[к]** авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер.* (Мәкаль)
   а) 1
   **ә) 2**
   б) 3
   в) 4

4. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.* (Мәкаль)
   а) һөнәр
   ә) ашарга
   **б) сорамый**
   в) ашата

5. ***Саран*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тар
   ә) тырыш
   б) тыйнак
   **в) юмарт**

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) чүлмәк

**ә) билбау**

б) кура җиләге

в) савыт-саба

7. Җөмләдәге исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сандугачны сайрарга өйрәтмиләр.* (Мәкаль)

а) баш килеш

ә) иялек килеше

б) юнәлеш килеше

**в) төшем килеше**

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Егет кешегә **җитмеш** төрле һөнәр дә аз.* (Мәкаль)

а) исем

ә) сыйфат

**б) сан**

в) фигыль

9. Боерык фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Кәкре агачсыз урман булмый.

ә) Агачтан яфрак төшми тормый.

б) Алма агачыннан ерак төшми.

**в) Алманың кызылына алданма.**

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Акылсыз башка алтын бүрек файда бирми.* (Мәкаль)

а) башка

ә) акылсыз

**б) бүрек**

в) алтын

## II. Башыгызны эшләтегез.

Диңгезне шырпы белән болгатып булмый. **(5 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле авазны һәм сүзләрне өстәп языгыз. **(8 балл)**

В хәрефе [в] һәм [**w**] авазларын белдерә. Сүзләрнең мәгънәләре **аңлатмалы** сүзлекләрдә күрсәтелә. Бер тамырдан ясалган сүзләр **тамырдаш** сүзләр дип атала. -га/-гә – **юнәлеш** килеше кушымчасы. Мин, син, ул – **зат** алмашлыклары. Ия **баш** килештәге зат алмашлыклары белән белдерелә ала.

Җөмләләр **тәмамланган** уйны белдерә. **Тиңдәш** кисәкләр бер-берсе белән тезүле бәйләнештә килә.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(3 балл)**

Рано вставай.
Не бойсы воды – мойся!
Вовремя пей, вовремя ешь.
(*Самуил Маршак*)

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

Без га**и**ләбез белән спорт яратабыз. Көн саен иртән паркта йөгерәбез. **Ә**нем белән абыем й**ө**з**ә**ргә яраталар. Мин хоккей белән ш**ө**г**ы**льләнәм.

**Һ**әр көнне без җиләк-җимеш ашыйбыз. Мин баллы ризык ашамыйм. Ул т**е**шләргә зыянлы.

2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(3 балл)**

көн – **төн**, баллы – **ачы/әче**, зыянлы – **файдалы**

2.2. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(3 балл)**

йөгерү – **чабу**, баллы – **татлы**, зыянлы – **зарарлы**

3. Сез нинди ризыклар ашарга яратасыз? Дөрес туклану ни өчен кирәк? Шул хакта 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдә кулланылган тел арты [**к**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Куркакның йодрыгы кесәсендә.* (Мәкаль)

**а) 1**
ә) 2
б) 3
в) 4

2. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Җәен йоклама, кышын өлгерерсең.* (Мәкаль)

**а) 1**
ә) 2
б) 3
в) 4

3. Сүзнең басымы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) у′-кы-мый-лар
**ә) у-кы′-мый-лар**
б) у-кы-мы′й-лар
в) у-кы-мый-ла′р

4. Синонимнарны билгеләгез. **(2 балл)**

а) җырлый, бии
ә) утыра, баса
б) йөгерә, атлый
**в) ялтырый, җемелди**

5. Фразеологизмның антоним парын билгеләгез. **(2 балл)**

***Балтасы суга төшү***

а) су кебек эчү
ә) утлы табага бастыру
б) агач атка атландыру
**в) түбәсе күккә тию**

6. Җөмләдәге ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бер карлыгач килү белән, яз башланмый.* (Мәкаль)

а) карлыгач
ә) килү
б) белән
**в) башланмый**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Кеше яраткан **эшен** яхшы эшли.* (Мәкаль)

а) баш килештә
**ә) төшем килешендә**
б) чыгыш килешендә
в) урын-вакыт килешендә

8. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) сары

ә) сарырак
б) сап-сары
**в) саргылт**

9. Җөмләдәге фигыльнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Батырлыгыңны мәйданда сынат.* (Мәкаль)
а) хәзерге заман хикәя фигыль
ә) үткән заман хикәя фигыль
б) киләчәк заман хикәя фигыль
**в) боерык фигыль**

10. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Көндезге эш кичке эштән көләр.* (Мәкаль)
а) көндезге
ә) эш
б) эштән
**в) көләр**

**II. Башыгызны эшләтегез.**

Яхшы җиргә төшкән орлык югалмас. **(5 балл)**

**III. Теоретик бирем.**

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(8 балл)**

[у] – калын, **иренләшкән** сузык аваз. Төлке – **исем** сүз төркеме, ә хәйләкәр – **сыйфат**. Җәй – **кыш** – антоним сүзләр. Чүп – **тамыр** исем, чүплек – ясалма исем. Сыер, сарык, чыпчык **нәрсә**? соравына җавап бирә. -дан/-дән – **чыгыш** килеше кушымчасы. Китте – **үткән** заман хикәя фигыль.

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Шигырьдәге җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**
Наступили холода.
Обернулась в лёд вода.
Длинноухий зайка серый
Обернулся зайкой белым.

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Әппәс исемле бер бәләкәй аю баласы яши икән урманда. Ул яз көне бакча казыган, бер түтәлгә кишер чәчкән. Кәбестә, кыяр да утырткан. Помидор белән шалкан да үстергән ул.

Көз җиткән. Яшелчәләр өлгергән. **Бәләкәй аю баласы кишерне дә алган, кәбестәне дә алган, кыяр белән помидорны да җыйган, шалканны да йолкыган.**

Аю урмандагы барлык җәнлекләрне яшелчәләр белән сыйлаган. Барысы да Әппәскә рәхмәт укыганнар. Кыш җиткән. Кыш җиткәч, аюлар кар

астындагы өннәренә кереп йокларга ята. Бәләкәй Әппәс тә кар астына куыш ясаган да йокларга яткан. (*Рабит Батулладан*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(1 балл) помидор, помидорны**

2.2. Текстта кулланылган антоним сүзләрне парлап языгыз. **(4 балл)** яз – **көз,** чәчкән – **җыйган,** утырткан – **алган/йолкыган,** үстергән – **йолкыган/алган** (төрле вариантта бирергә мөмкиннәр)

2.3. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләдәге тиндәш кисәкләрне күчереп языгыз. **(3 балл) алган, алган, җыйган, йолкыган; кыяр, помидорны**

3. Әппәс, йоклаганда, нинди төш күрер икән? Фикерләрегезне 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп оештырыгыз. (**10 балл**)

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 62**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге сузык авазларның санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Аз сөйләгән аз ялгышыр.* (Мәкаль)
   а) 6
   ә) 7
   **б) 8**
   в) 9

2. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең транскрипциясен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Былтыр **кысканга** быел кычкырмыйлар.* (Мәкаль)
   а) [кысканга]
   ә) [косканга]
   б) [қысқанга]

**в) [қысқанға]**

3. Җөмләдәге ачык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Ай якты да, җылытмый.* (Мәкаль)

а) 2

**ә) 3**

б) 4

в) 5

4. Фразеологик әйтелмә булмаган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) биш бармак**

ә) биш көнлек дөнья

б) биш былтыр

в) биш бармак кебек

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

***Сай*** *елга шалтырап ага,* ***тирән*** *елга – тавышсыз.* (Мәкаль)

а) синонимнар

ә) омонимнар

**б) антонимнар**

в) фразеологик әйтелмәләр

6. Ясалма сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) кызыл

ә) матур

б) җылы

**в) җиләс**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Дус* ***акчадан*** *кыйммәт.* (Мәкаль)

а) иялек килешендә

ә) юнәлеш килешендә

**б) чыгыш килешендә**

в) урын-вакыт килешендә

8. Күләм-чама рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) җәяү

ә) ерак

**б) күп**

в) кышын

9. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Кайда коймак, шунда кунак.* (Мәкаль)
а) зат алмашлыгы, исем, зат алмашлыгы, исем
ә) сорау алмашлыгы, фигыль, күрсәтү алмашлыгы, исем
б) сорау алмашлыгы, фигыль, сорау алмашлыгы, исем
**в) сорау алмашлыгы, исем, күрсәтү алмашлыгы, исем**

10. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кеше арасында кеше бул!* (Мәкаль)
а) хикәя
ә) сорау
**б) боеру**
в) тойгылы

## II. Башыгызны эшләтегез.

Ялкау кешенең җилкәсе чокыр булыр. **(5 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Хәрефләрне **күрәбез**, язабыз һәм укыйбыз. [ң], [щ], [х], [һ] – парсыз **саңгырау** тартыклар. Телдә яңа гына барлыкка килеп кулланыла башлаган сүзләр **неологизмнар** дип атала. Ак – **кара** – антоним сүзләр. Балык – тамыр исем, балыкчы – **ясалма** исем. Башла, дуслаш – **исемнән** фигыль ясалган. -дан/-дән, -тан/-тән – **чыгыш** килеше кушымчасы. Исемнәр берлек һәм **күплек** санда килә.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Табышмакның эчтәлеген татар теленә хикәя формасында тәрҗемә итеп языгыз. **(5 балл)**

Дел у меня немало:
Я белым одеялом
Всю землю укрываю.
В лёд реки убираю.
Белю поля, дома.
А зовут меня зима.

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(4 балл)**

Ренат рәсем төш**е**рергә бик ярата. Ул ө**й**ләр ясый, **й**өгерек атлар да эшләп куя.

Беркөнне малай кәг**а**зь тапты, карандаш алды да рәсем ясарга утырды. Тик менә нәрсә ясарга? Машинаны ул ясый белә, танк рәсемен матур итеп эшли ала. Нәрсә ясарга с**о**ң? Шулай аптырап торганда, аның күзе өстәлдәге

китапка тө̲ште. Китапның ачылып торган битендә менә дигән рәсем: дин̲гезнең зәң̲гәр дулкыннарын ярып, бер зур кораб бара. (*Абдулла Алиштан*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(4 балл) Ренат, машинаны, китапка, китапның**
2.2. Сүзнең антоним парын языгыз. **(1 балл)**
тапты – **югалтты**
2.3. Кушма сүзне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. **(2 балл)**
**беркөнне** (бер – тамыр, көн – тамыр, -не – бәйләгеч кушымча, беркөн – нигез)
2.4. ***Зәңгәр*** сыйфатын дәрәҗәләр белән төрләндереп языгыз. **(2 балл)**
**зәңгәр, зәңгәррәк, зәп-зәңгәр, зәңгәрсу**
2.5. Икенче җөмләнең иясен күчереп языгыз. **(1 балл) ул**

3. Сезнең алдыгызга ак кәгазь һәм төсле карандашлар куйсалар, сез нинди рәсем ясар идегез? Ни өчен? Фикерләрегезне 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп оештырыгыз. (**10 балл**)

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 64**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясе чагылыш тапкан сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Тозсыз сүздән тозлы ботка тәмлерәк.* (Мәкаль)
а) 1
**ә) 2**
б) 3

в) 4

2. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәрешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкауның кулы* ***куеныннан*** *чыкмас.* (Мәкаль)

а) тартыклар чиратлашуы

ә) яңгыраулыкта охшашлану

б) ирен ассимиляциясе

**в) борын ассимиляциясе**

3. Җөмләдәге калын хәрефләр белән күрсәтелгән сүз урынына туры килә торган фразеологизмны билгеләгез. **(2 балл)**

*Әнием* ***эшсез*** *йөрүчеләрне яратмый.*

а) авыз ерып

ә) җиде кат күккә менеп

**б) җил куып**

в) сүзгә кесәгә керми

4. ***Иҗтиһад*** сүзенең бүгенге көндә кулланыла торган вариантын билгеләгез. **(2 балл)**

**а) тырышлык**

ә) хат

б) көнчыгыш

в) акыл

5. Ясалма исемне билгеләгез. **(2 балл)**

а) балам

**ә) сөйләм**

б) түшәм

в) көлмәк

6. Иярүче теркәгечне билгеләгез. **(2 балл)**

а) ләкин

**ә) чөнки**

б) һәм

в) яки

7. Сәбәп-максат рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) мамыктай

ә) аз

б) бүген

**в) тикмәгә**

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә карaганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Дөядәй буең* ***булганчы****, төймәдәй уең булсын.* (Мәкаль)

а) хикәя фигыль

ә) шарт фигыль

**б) хәл фигыль**

в) инфинитив

9. Сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) тәмле җиләк**

ә) җиләк

б) яшелчә, җиләк-җимеш

в) кура җиләге

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Тырышкан табар, ташка кадак кагар.* (Мәкаль)

**а) тырышкан**

ә) ташка

б) кадак

в) кагар

## II. Башыгызны эшләтегез.

Карбыз кабыгы аркасында батыр җиргә егыла. **(6 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар сүзләрендә сузыклар я калын гына, я **нечкә** генә булалар.**Тартык** авазлар үзләре генә иҗек барлыкка китерә алмыйлар. Охшаш мәгънәле сүзләр **синонимнар** дип атала. Сүзгә ялганып килә торган кисәк **кушымча** дип атала. РФ – тезмә сүзнең **баш** хәрефләреннән ясалган кыскартылма исем. Баллы – предметның **тәмен** белдерә торган сыйфат. Асыл сыйфатлар **дәрәҗә** белән төрләнәләр. Фигыльләр **барлыкта** һәм юклыкта килә ала.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Белым ровным слоем покрыл снег всю землю. Поля и лесные поляны теперь – как гладкие чистые страницы какой-то гигантской книги.

Днём идёт снег. Кончится – страницы чистые. Утром придёшь – белые страницы покрыты множеством таинственных значков, черточек, точек, запятых. *(Виталий Бианки)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Кышкы урманда

Кыш – художник, с**о**кланырлык итеп,

Ямь, матурлык биргән урманга.

Бар җирдә дә йомшак кар җәймәсе:
Аланнар да ап-ак, юллар да.
**Өсләренә көяз чыршыларның**
**Ак ефәктәй бәсләр уралган.**
Таң тууга, энҗе бөртекләре
Балкый анда алсу нурлардан. *(Әнәс Кари)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) художник**

2.2. ***Урманга*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [урманға]**

2.3. Сүзләрнең синонимнарын языгыз. **(2 балл)**

художник – **рәссам,** көяз – **купшы, матур**

2.4. ***Җәймәсе*** сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. **(2 балл)**

**җәймәсе** (җәй – тамыр, -мә – ясагыч кушымча, -се – бәйләгеч кушымча, җәймә – нигез)

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә җөмлә кисәкләре ягыннан анализ ясагыз. **(4 балл)**

Әсләреиә(у.х) көяз чыршыларның
Ак ефәктәй бәсләр(г.и.) уралган(г.ф.х.).

3. Кышкы табигатьнең матурлыгы нидә? Фикерләрегезне 8-10 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәрешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Кош **кунмаган** агач юк.* (Мәкаль)
а) тартыклар чиратлашуы
ә) яңгыраулыкта охшашлану
**б) ирен ассимиляциясе**
в) борын ассимиляциясе

2. Җөмләдәге ябык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Баш сау булса, бүрек табылыр.* (Мәкаль)

**а) 5**
ә) 6
б) 7
в) 8

3. Җөмләдәге омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Миләүшә бакчасында лилия, миләүшә һәм ләлә чәчәкләрен үстерә.*

а) саф лексик
**ә) омофоннар**
б) омографлар
в) омоформалар

4. Фразеологик әйтелмә булмаган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

**а) бишкә тапкырлау**
ә) бишкә төрләнү
б) бишкә ярылу
в) бишкә алып бергә саткан

5. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүлмәдә зәңгәр күлмәкле, ефәк шарфлы яшь кенә бер хатын утыра иде.* (Гомәр Бәширов)

а) 2
**ә) 3**
б) 4
в) 5

6. Ияртүче теркәгечне билгеләгез. **(2 балл)**

а) әмма
ә) вә
б) яисә
**в) ягъни**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Кунак туймаса **да** рәхмәт әйтер.* (Мәкаль)

а) урын-вакыт килеше кушымчасы
**ә) кисәкчә**
б) теркәгеч
в) ярдәмче фигыль

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ир-егет үзе өчен туа, иле өчен үлә.* (Мәкаль)

**а) ир-егет**

ә) үзе
б) иле
в) туа, үлә

9. Мәкальләр арасыннан бер составлы фигыль җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Һәр өйнең үз гадәте бар.
ә) Гаилә – бәхет ачкычы.
**б) Өйдәге тавышны тышка чыгарма.**
в) Ата-бабалы кеше – тамырлы имән.

10. Мәкальләр арасыннан кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Әнкәм йорты – алтын бишек.
ә) Ана – шәфкать диңгезе.
б) Кызыңның төсен мактама, эшен макта.
**в) Атасы барның бәхете бар.**

## II. Башыгызны эшләтегез.

Ата угылының үзеннән шәбрәк булуын тели. **(6 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

[у], [ү], [о], [ө] – иренләшкән **сузык** авазлар. Сузык авазга тәмамланган иҗек **ачык** иҗек дип атала. Искергән сүзләр икегә бүленә: **архаизмнар** һәм **тарихи** сүзләр. Бәйләгеч кушымчаларга исемнең **килеш** һәм тартым кушымчалары керә. Алмашлык – исемне, сыйфатны, **санны** һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме. Аваз ияртемнәреннән исем һәм **фигыль** ясала. Төзелеше ягыннан ия **гади** һәм тезмә була.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

Есть такие страны, где не растут леса. Есть такие люди, которые не знают, что такое лес. Но всё-таки люди не могли бы обойтись без леса. Лес это не только грибы, ягоды, лекарственные травы. Лес очищает воздух и выделяет кислород. Вот почему так важен для человека лес. *(Юрий Дмитриев)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

**Киң бездә далалар, урманнар,**
**Күп бездә диңгезләр, елгалар.**
Безнең ил – туганлык д**ә**рьясы.
Һич ти**н**е юк аның д**ө**ньяда.
Безнең бай җирләрдә бар да бар.
Мәрмәрләр, җәү**һ**әрләр табылалар.
Һәркемгә бәхетле яшәргә,

Иркенләп суларга һава бар.

(*Әхмәт Ерикәй*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) дәрьясы, дөньясы**

2.2. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(2 балл)**

киң – **тар,** күп – **аз**

2.3. ***Һәркемгә*** сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. **(2 балл)**

**(*Һәр – тамыр, кем – тамыр, -гә – бәйләгеч кушымча, һәркем – нигез*)**

2.4. ***Бар*** сүзләре кайсы сүз төркеменә карый? **(2 балл)**

***бар(ал.) бар(х.с.).***

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз. **(3 балл)**

(1)Киң бездә далалар, урманнар,

(2)Күп бездә диңгезләр, елгалар.

Бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Схема сызылган булырга тиеш!

3. ***"Ил эче алтын бишек"*** диелә халык мәкалендә. ***"Ватан барыннан да газиз"*** дигән әйтем дә бар. Сез бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Олының сүзен оекка кыстыр.* (Мәкаль)

а) 1

**ә) 2**

б) 3
в) 4

2. Җөмләдәге ТСТ (тартык+сузык+тартык) иҗек калыбының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Ашап эчкәндә дус яхшы, кайгылы көндә туган яхшы.* (Мәкаль)
а) 5
ә) 6
**б) 8**
в) 10

3. Җөмләдәге омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Бу – зур бүлмә, син аны икегә бүлмә!*
а) саф лексик
ә) омофоннар
б) омографлар
**в) омоформалар**

4. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Эшсез килеп эшленең эшен калдырыр.* (Мәкаль)
а) 1
**ә) 2**
б) 3
в) 4

5. ***Кайнар*** сыйфатының сыйфатланмышын билгеләгез. **(2 балл)**
а) көн
**ә) аш**
б) җәй
в) тун

6. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
*Буласы җимеш чәчәгеннән үк беленә.* (Мәкаль)
а) сыйфат фигыль, исем, исем, кисәкчә, сыйфат фигыль
ә) хикәя фигыль, исем, исем, кисәкчә, хикәя фигыль
**б) сыйфат фигыль, исем, исем, кисәкчә, хикәя фигыль**
в) шарт фигыль, исем, исем, кисәкчә, хикәя фигыль

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
*Кешегә ярыйм **дип** ярылып үлеп булмый.* (Мәкаль)
**а) бәйлек сүз**
ә) бәйлек
б) хәл фигыль

в) ияртүче теркәгеч

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

***Кызыңның*** *төсен мактама, эшен макта.* (Мәкаль)

а) ия

ә) хәбәр

б) тәмамлык

**в) аергыч**

9. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Эшнең боткасы тәмле.* (Мәкаль)

а) гомум үтәүчеле бер составлы, тулы

ә) гомум үтәүчеле бер составлы, ким

б) билгеле үтәүчеле бер составлы, тулы

**в) ике составлы, тулы**

10. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ат булмаганда, ишәк тә ярап куя.* (Мәкаль)

а) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә

ә) синтетик иярчен күләм җөмлә

**б) синтетик иярчен вакыт җөмлә**

в) аналитик иярчен шарт җөмлә

## II. Башыгызны эшләтегез.

Тату туганнар таштан койма койганнар. **(5 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

**Тартык** авазга тәмамланган иҗек  ябык иҗек дип атала. **Бер** иҗекле сүзгә басым билгесе куелмый. **Диалекталь** һәм һөнәрчелек сүзләре – кулланылышы чикләнгән сүзләр. Исемнәрдә күплек сан һәм иркәләү-кечерәйтү кушымчалары – **модальлек** кушымчалары дип атала. **Исем** фигыль рус телендә юк. Сәбәп хәле **үткән** заманга, ә максат хәле **киләчәк** заманга карый. Теркәгечле тезмә кушма җөмлә компонентлары арасына **өтер** куела.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(8 балл)**

На столе лежит тёплый хлеб. Он так вкусно пахнет!

Большой путь проделал хлеб. Сначала золотые руки зерно посеяли. Урожай растили.

В золотом стебельке выросло зерно. Каждое утро серебряной росой умывался каждый колосок. *(Т.Коломец)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Бакчачы

Бик у**ң**ган безнең бакчачы бабай,
Яше үзенең туксанда бугай.
Ул кояш белән бергә кузгала,
К**ө**рә**г**ен ала, жи**ң**ен сызгана.
Түтәлләр казый, гөлләр утырта,
Алмагачларның башларын к**ы**рка.

Түтәлне тутырып үсә җиләкләр,
Нәр**к**ис, миләүшә, сөмбел һәм мәкләр.
Язын бакчага кайталар кошлар –
Безнең кадерле канатлы дуслар.
**Үлсә дә бер көн безнең бакчачы,**
**Һәр яз яшәреп яшәр бакчасы.**

(*Муса Җәлил*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) сөмбел**

2.2. ***Кадерле*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [қәдэрлэ]**

2.3. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(2 балл)**

уңган – **ялкау,** язын – **көзен**

2.4. ***Алмагачларның*** сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. **(3 балл)**
***(алма – тамыр, агач – тамыр, -лар – модальлек кушымча, -ның – бәйләгеч кушымча, алмагач – нигез)***

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз. **(4 балл)**

(1)Үлсә дә бер көн безнең бакчачы,
(2)Һәр яз яшәреп яшәр бакчасы.

(2 – б.ж., 1 – с.и.к.ж. -сә дә – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!

3. ***"Хезмәт төбе – хәзинә"*** диелә халык мәкалендә. ***"Эш батыры – ил батыры"*** дигән әйтем дә бар. Сез бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**ВАРИАНТ 1**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәрешен билгеләгез. **(2 балл)**

*Күршең **үзеңнән** яхшырак булсын.* (Мәкаль)

а) ирен ассимиляциясе
ә) яңгыраулыкта охшашлану
б) тел арты ассимиляциясе
**в) борын ассимиляциясе**

2. Җөмләдәге ТСТ (тартык+сузык+тартык) иҗек калыбының санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Уеныңны кайда уйнасаң, шунда калсын.* (Мәкаль)

а) 4
ә) 5
**б) 6**
в) 8

3. Фразеологизмны билгеләгез. **(2 балл)**

**а) чәчләр үрә тору**
ә) чәчләр юешләнү
б) чәчне үрү
в) чәчне юу

4. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Эшләнеп бетмәгән эшнең бәясе тишекле бер тиен.* (Мәкаль)

а) 1
**ә) 2**
б) 3
в) 4

5. Җөмләдәге фигыльләрнең төркемчәләрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Кергәнче чыгар җиреңне кара.* (Мәкаль)

а) хәл фигыль, хикәя фигыль, боерык фигыль

ә) хәл фигыль, хикәя фигыль, исем фигыль
б) сыйфат фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль
**в) хәл фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль**

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
*Агач җимеше* ***белән****, адәм эше* ***белән****.* (Мәкаль)
а) тезүче теркәгечләр
ә) ияртүче теркәгечләр
**б) бәйлекләр**
в) бәйлек сүзләр

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**
*Яралы* ***кошка*** *таш атмыйлар.* (Мәкаль)
а) ия
ә) урын хәле
**б) тәмамлык**
в) аергыч

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Сүз күп җирдә эш аз була.* (Мәкаль)
а) гади җөмлә
ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
**в) иярченле кушма җөмлә**

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Ялкауның җиренә бодай чәчсәң дә, билчән үсәр.* (Мәкаль)
а) аналитик иярчен аергыч җөмлә
ә) аналитик иярчен урын җөмлә
б) синтетик иярчен шарт җөмлә
**в) синтетик иярчен кире җөмлә**

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Китә башласам, газиз әнкәем,*
*Яшь тулы күзең түбән иясең.* (Шәмсия Җиһангирова)
а) 1
ә) 2
**б) 3**
в) 4

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җәяүле атлыга юлдаш була алмый. **(6 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

**Кире** ассимиляция язуда чагылыш тапмый. Капма-каршы мәгънәле сүзләр **антонимнар** дип атала. Музфак – сүзләрнең **беренче** иҗекләреннән кыскартылып ясалган исем. Хәл фигыль – **затланышсыз** фигыль. Теркәгечләр ике төрле була: **тезүче** һәм **ияртүче**. Бер компоненты икенчесенә ияреп килгән кушма җөмлә **иярченле** кушма җөмлә дип атала. **Синтетик** чаралар һәрвакыт иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьдәге җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(7 балл)**

Дружба это дар нам свыше.
Дружба это свет в окне.
Друг всегда тебя услышит.
Он не бросит и в беде.
Но не каждому дано
Знать, что дружба есть на свете,
Что с друзьями жить легко,
Веселее с ними вместе. *(Юлия Белоусова)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Чулпан алманы кояшка күтәреп карады. Аннан соң вазага да салды. **Соңыннан ул алманы өстәл өстендә тәгәрәтеп карады.** Алманың исеннән авызына сулар килде. Бу зур һәм матур алманы Чулпан ашарга кызганды.

Менә Чулпан дәресләрен әзерләп бетерде. Ул алманы кәгазьгә төрде дә мәктәпкә алып китте.

Бу зур алманы Чулпан иптәшләре белән бүлешеп ашады. Төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар. Яз җиткәч, яшь алмагачлар үсәр. (*Идрис Туктардан*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) соңыннан, өстендә, төрде**

2.2. ***Чулпанга*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [чулпаңға]**

2.3. ***Авызына сулар килде*** фразеологизмының мәгънәсен аңлатыгыз. **(1 балл) (кызыгу, ашыйсы килү)**

2.4. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләсендәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә карагалыгын языгыз. **(4 балл)**

***Соңыннан(р.) ул(ал.) алманы(ис.) өстәл(ис.) өстендә(б.с.) тәгәрәтеп(хәл ф.) карады(хик.ф.).***

2.5. Кушма җөмләне табыгыз, синтаксик анализ ясагыз. **(4 балл)**

(1)Яз җиткәч, (2)яшь алмагачлар үсәр.

(2 – б.ж., 1 – с.и.в.ж. -кәч – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызыларга тиеш!

3. ***“Юмартлык белән батырлык икесе бер чишмәдән ага”*** диелә халык мәкалендә. ***“Иң батыр кеше – үз нәфесен җиңүче”*** дигән әйтем дә бар. Сез бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**ВАРИАНТ 2**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Галимнең бер көне наданның бөтен гомеренә тора.* (Мәкаль)

а) 1;
ә) 2;
**б) 3;**
в) 4.

2. Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кулланылу активлыгы буенча кайсы төркемгә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кеше* ***яңлыша-яңлыша*** *галим булыр.* (Мәкаль)

**а) архаизм;**
ә) тарихи сүз;
б) неологизм;
в) фразеологизм.

3. Җөмләдәге ясалма сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Атаң-анаң – чын дустың, дус-ишләрең - юлдашың.* (Мәкаль)

а) 1;
ә) 2;
**б) 3;**
в) 4.

4. Җөмләдәге алмашлыкларның төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Эт үз койрыгын үзе күтәрмәсә, аны кем күтәрә?* (Мәкаль)

а) билгеләү, тартым, зат, сорау;
ә) билгеләү, билгеләү, сорау, сорау;
б) тартым, күрсәтү, билгеләү, сорау;
**в) билгеләү, билгеләү, зат, сорау.**

5. Җөмләдәге фигыльләрнең төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Уйламыйча эшләсәң, чирләмичә үләрсең.* (Мәкаль)

а) хикәя фигыль, шарт фигыль, хәл фигыль, шарт фигыль;

ә) шарт фигыль, шарт фигыль, хәл фигыль, хәл фигыль;

**б) хәл фигыль, шарт фигыль, хәл фигыль, хикәя фигыль;**

в) хәл фигыль, сыйфат фигыль, инфинитив, сыйфат фигыль.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Агач җимеше* ***белән****, адәм эше* ***белән****.* (Мәкаль)

а) тезүче теркәгечләр

ә) иярүче теркәгечләр

**б) бәйлекләр**

в) бәйлек сүзләр

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Яралы* ***кошка*** *таш атмыйлар.* (Мәкаль)

а) ия

ә) урын хәле

**б) тәмамлык**

в) аергыч

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сүз күп җирдә эш аз була.* (Мәкаль)

а) гади җөмлә

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

**в) иярченле кушма җөмлә**

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкауның җиренә бодай чәчсәң дә, билчән үсәр.* (Мәкаль)

а) аналитик иярчен аергыч җөмлә

ә) аналитик иярчен урын җөмлә

б) синтетик иярчен шарт җөмлә

**в) синтетик иярчен кире җөмлә**

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Китә башласам, газиз әнкәем,*
*Яшь тулы күзең түбән иясең.* (Шәмсия Җиһангирова)

а) 1

ә) 2

**б) 3**
в) 4

**II. Башыгызны эшләтегез.**

Җәяүле атлыга юлдаш була алмый. **(6 балл)**

**III. Теоретик бирем.**

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

**Кире** ассимиляция язуда чагылыш тапмый. Капма-каршы мәгънәле сүзләр **антонимнар** дип атала. Музфак – сүзләрнең **беренче** иҗекләреннән кыскартылып ясалган исем. Хәл фигыль – **затланышсыз** фигыль. Теркәгечләр ике төрле була: **тезүче** һәм **ияртүче**. Бер компоненты икенчесенә ияреп килгән кушма җөмлә **иярченле** кушма җөмлә дип атала. **Синтетик** чаралар һәрвакыт иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр.

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Шигырьдәге җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(7 балл)**

Дружба это дар нам свыше.
Дружба это свет в окне.
Друг всегда тебя услышит.
Он не бросит и в беде.
Но не каждому дано
Знать, что дружба есть на свете,
Что с друзьями жить легко,
Веселее с ними вместе. *(Юлия Белоусова)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Чулпан алманы кояшка күтәреп карады. Аннан соң вазага да салды. **Соңыннан ул алманы өстәл өстендә тәгәрәтеп карады.** Алманың исеннән авызына сулар килде. Бу зур һәм матур алманы Чулпан ашарга кызганды.

Менә Чулпан дәресләрен әзерләп бетерде. Ул алманы кәгазьгә төрде дә мәктәпкә алып китте.

Бу зур алманы Чулпан иптәшләре белән бүлешеп ашады. Төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар. Яз җиткәч, яшь алмагачлар үсәр. (*Идрис Туктардан*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) соңыннан, өстендә, төрде**
2.2. ***Чулпанга*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [чулпаңға]**
2.3. ***Авызына сулар килде*** фразеологизмының мәгънәсен аңлатыгыз. **(1 балл) (кызыгу, ашыйсы килү)**
2.4. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләсендәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын языгыз. **(4 балл)**

***Соңыннан(р.) ул(ал.) алманы(ис.) өстәл(ис.) өстендә(б.с.) тәгәрәтеп(хәл ф.) карады(хик.ф.).***

2.5. Кушма җөмләне табыгыз, синтаксик анализ ясагыз. **(4 балл)**

(1)Яз житкәч, (2)яшь алмагачлар үсәр.

(2 – б.җ., 1 – с.и.в.җ. -кәч – бәйләүче чара). Бу – нярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!

3. ***“Юмартлык белән батырлык икесе бер чишмәдән ага”*** днелә халык мәкалендә. ***“Иң батыр кеше – үз нәфесен җиңүче”*** дигән әйтем дә бар. Сез бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӘРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**ВАРИАНТ 3**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен ассимиляциясе чагылыш тапкан сүз кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *Мең чакрымлык юл да бер адымнан башлана.*
   ә) *Кызыңның төсен мактама, эшен макта.*
   **б) *Ир бала унбиштә – өй хуҗасы.***
   в) *Юлны яхшы белгән арымас.*

2. Икеюллыкта бирелгән омонимнарның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Чәчәк тоткан кулларына Чәчәк,*
   *Шатлык тулы күзләрендә – чәчәк.* (Ямаш Игәнәй)
   а) саф;
   **ә) омофон;**
   б) омограф;
   в) омоформа.

3. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең синонимы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Сандугач*** *үз җирендә сайрый.* (Мәкаль)
   а) *саескан*;
   **ә) *былбыл*;**
   б) *чәүкә*;
   в) *чыпчык*.

4. Мәкальдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Картлыгың бәхетле булсын дисәң, яшьлегеңдә ялкау булма.* (Мәкаль)
   **а) *картлыгың, бәхетле, яшьлегеңдә*;**
   ә) *картлыгың, яшьлегеңдә*;
   б) *картлыгың, бәхетле, яшьлегеңдә, ялкау*;
   в) *картлыгың, бәхетле, яшьлегеңдә, ялкау, булма*.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ахмакка биргән киңәш далага аткан ук* ***кебек.*** (Мәкаль)

а) бәйлек сүз;

ә) кисәкчә;

**б) баш килешне таләп итүче бәйлек;**

в) хәбәрлек сүз.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Агач җимеше* ***белән****, адәм эше* ***белән****.* (Мәкаль)

а) тезүче теркәгечләр

ә) ияртүче теркәгечләр

**б) бәйлекләр**

в) бәйлек сүзләр

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Яралы* ***кошка*** *таш атмыйлар.* (Мәкаль)

а) ия

ә) урын хәле

**б) тәмамлык**

в) аергыч

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сүз күп җирдә эш аз була.* (Мәкаль)

а) гади җөмлә

ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

**в) иярченле кушма җөмлә**

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкауның җиренә бодай чәчсәң дә, билчән үсәр.* (Мәкаль)

а) аналитик иярчен аергыч җөмлә

ә) аналитик иярчен урын җөмлә

б) синтетик иярчен шарт җөмлә

**в) синтетик иярчен кире җөмлә**

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Китә башласам, газиз әнкәем,*
*Яшь тулы күзең түбән иясең.* (Шәмсия Җиһангирова)

а) 1

ә) 2

**б) 3**

в) 4

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җәяүле атлыга юлдаш була алмый. **(6 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

**Кире** ассимиляция язуда чагылыш тапмый. Капма-каршы мәгънәле сүзләр **антонимнар** дип атала. Музфак – сүзләрнең **беренче** иҗекләреннән кыскартылып ясалган исем. Хәл фигыль – **затланышсыз** фигыль. Теркәгечләр ике төрле була: **тезүче** һәм **иярүче**. Бер компоненты икенчесенә ияреп килгән кушма җөмлә **иярченле** кушма җөмлә дип атала. **Синтетик** чаралар һәрвакыт иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьдәге җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(7 балл)**

Дружба это дар нам свыше.
Дружба это свет в окне.
Друг всегда тебя услышит.
Он не бросит и в беде.
Но не каждому дано
Знать, что дружба есть на свете,
Что с друзьями жить легко,
Веселее с ними вместе. *(Юлия Белоусова)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Чулпан алманы кояшка күтәреп карады. Аннан соң вазага да салды. **Соңыннан ул алманы өстәл өстендә тәгәрәтеп карады.** Алманың исеннән авызына сулар килде. Бу зур һәм матур алманы Чулпан ашарга кызганды.

Менә Чулпан дәресләрен әзерләп бетерде. Ул алманы кәгазьгә төрде дә мәктәпкә алып китте.

Бу зур алманы Чулпан иптәшләре белән бүлешеп ашады. Төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар. Яз җиткәч, яшь алмагачлар үсәр. (*Идрис Туктардан*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) соңыннан, өстендә, төрде**

2.2. ***Чулпанга*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [чулпаңға]**

2.3. ***Авызына сулар килде*** фразеологизмының мәгънәсен аңлатыгыз. **(1 балл) (кызыгу, ашыйсы килү)**

2.4. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләсендәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын языгыз. **(4 балл)**

***Соңыннан(р.) ул(ал.) алманы(ис.) өстәл(ис.) өстендә(б.с.) тәгәрәтеп(хәл ф.) карады(хик.ф.).***

2.5. Кушма җөмләне табыгыз, синтаксик анализ ясагыз. **(4 балл)**

(1)Яз җиткәч, (2)яшь алмагачлар үсәр.

(2 – б.җ., 1 – с.и.в.җ. -кәч – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!

3. ***"Юмартлык белән батырлык икесе бер чишмәдән ага"*** диелә халык мәкалендә. ***"Иң батыр кеше – үз нәфесен җиңүче"*** дигән әйтем дә бар. Сез бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӘРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӘЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2023-2024 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**ВАРИАНТ 4**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Борын тартыкларының барысы да кулланылган җавапны билгеләгез. **(2 балл)**
*а) Кызлар кояш баеганны күрергә тау башына менделәр.*
*ә) Салават белән Алмаз – авылдашлар.*
**б) Әтием кибеттән яңа пешкән икмәк сатып алды.**
*в) Равил чаңгы шуарга яратмый.*
.

2. Җөмләдәге ТСТ (тартык+сузык+тартык) иҗек калыбының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Уеныңны кайда уйнасаң, шунда калсын.* (Мәкаль)
а) 4
ә) 5
**б) 6**
в) 8

3. Фразеологизмны билгеләгез. **(2 балл)**
**а) чәчләр үрә тору**
ә) чәчләр юешләнү
б) чәчне үрү
в) чәчне юу

4. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Эшләнеп бетмәгән эшнең бәясе тишекле бер тиен.* (Мәкаль)
а) 1
**ә) 2**
б) 3
в) 4

5. Җөмләдәге фигыльләрнең төркемчәләрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кергәнче чыгар җиреңне кара.* (Мәкаль)
а) хәл фигыль, хикәя фигыль, боерык фигыль
ә) хәл фигыль, хикәя фигыль, исем фигыль
б) сыйфат фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль

**в) хәл фигыль, сыйфат фигыль, боерык фигыль**

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Агач җимеше **белән**, адәм эше **белән**.* (Мәкаль)
а) тезүче теркәгечләр
ә) ияртүче теркәгечләр
**б) бәйлекләр**
в) бәйлек сүзләр

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Яралы **кошка** таш атмыйлар.* (Мәкаль)
а) ия
ә) урын хәле
**б) тәмамлык**
в) аергыч

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сүз күп җирдә эш аз була.* (Мәкаль)
а) гади җөмлә
ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
**в) иярченле кушма җөмлә**

9. Бирелгән җөмләдәге иярчен компонентның төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкауның җиренә бодай чәчсәң дә, билчән үсәр.* (Мәкаль)
а) аналитик иярчен аергыч җөмлә
ә) аналитик иярчен урын җөмлә
б) синтетик иярчен шарт җөмлә
**в) синтетик иярчен кире җөмлә**

10. Җөмләдәге компонентлар санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Китә башласам, газиз әнкәем,*
*Яшь тулы күзең түбән иясең.* (Шәмсия Җиһангирова)
а) 1
ә) 2
**б) 3**
в) 4

## II. Башыгызны эшләтегез.

Җәяүле атлыга юлдаш була алмый. **(6 балл)**

## III. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

**Кире** ассимиляция язуда чагылыш тапмый. Капма-каршы мәгънәле сүзләр **антонимнар** дип атала. Музфак – сүзләрнең **беренче** иҗекләреннән кыскартылып ясалган исем. Хәл фигыль – **затланышсыз** фигыль. Теркәгечләр ике төрле була: **тезүче** һәм **ияртүче**. Бер компоненты икенчесенә ияреп килгән кушма җөмлә **иярченле** кушма җөмлә дип атала. **Синтетик** чаралар һәрвакыт иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьдәге җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(7 балл)**

Дружба  это дар нам свыше.
Дружба  это свет в окне.
Друг всегда тебя услышит.
Он не бросит и в беде.
Но не каждому дано
Знать, что дружба есть на свете,
Что с друзьями жить легко,
Веселее с ними вместе. *(Юлия Белоусова)*

2. Төшеп калган хәрефләрне языгыз. **(3 балл)**

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Чулпан алманы кояшка күтәреп карады. Аннан соң вазага да салды. **Соңыннан ул алманы өстәл өстендә тәгәрәтеп карады.** Алманың исеннән авызына сулар килде. Бу зур һәм матур алманы Чулпан ашарга кызганды.

Менә Чулпан дәресләрен әзерләп бетерде. Ул алманы кәгазьгә төрде дә мәктәпкә алып китте.

Бу зур алманы Чулпан иптәшләре белән бүлешеп ашады. Төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар. Яз җиткәч, яшь алмагачлар үсәр. (*Идрис Туктардан*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) соңыннан, өстендә, төрде**
2.2. ***Чулпанга*** сүзенең транскрипциясен языгыз **(2 балл) [чулпаңға]**
2.3. ***Авызына сулар килде*** фразеологизмының мәгънәсен аңлатыгыз. **(1 балл) (кызыгу, ашыйсы килү)**
2.4. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләсендәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын языгыз. **(4 балл)**
***Соңыннан(р.) ул(ал.) алманы(ис.) өстәл(ис.) өстендә(б.с.) тәгәрәтеп(хәл ф.) карады(хик.ф.).***
2.5. Кушма җөмләне табыгыз, синтаксик анализ ясагыз. **(4 балл)**
(1)Яз җиткәч, (2)яшь алмагачлар үсәр.
(2 – б.җ., 1 – с.и.в.җ. -кәч – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!
3. ***“Юмартлык белән батырлык икесе бер чишмәдән ага”*** диелә халык мәкалендә. ***“Иң батыр кеше – үз нәфесен җиңүче”*** дигән әйтем дә бар. Сез

бу турыда ничек уйлыйсыз? Фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (**12 балл**)